**СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru


Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның «26» феврале № 52-157

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл Советы 16.11.2016 № 20-45 «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 16.11.2016 № 20-45 карарына («Җир салымы турында»: 31.08.2017 № 30-72; 14.11.2018 № 46-110; 23.09.2019 № 54-134; 26.10.2020 № 3-7; 12.03.2021 № 9-21; 18.12.2023 № 41-130; 27.11.2024 № 48-150;) ( алга таба-карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарда 3.2 нче пунктның икенче абзацында. «оешмаларга һәм» сүзләрен «муниципаль» сүзенә алмаштырырга»;

1.2. Карарны түбәндәге эчтәлекле 4 пункт белән тулыландырырга:

«4. Салым түләүчеләр - үзләренә карата хисап чоры квартал буларак билгеләнгән юридик затлар агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталлары тәмамланганнан соң салым буенча аванс түләүләре суммаларын җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бере итеп исәплиләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Шахмай
авыл җирлеге башлыгы Н.М. Илалова